КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 июнь г.Казань № 514

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Р.А.Шәйхетдиновны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары итеп билгеләп кую турында» 2019 елның 5 июнендәге, ПУ-311 номерлы; «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2019 елның 5 июнендәге ПУ-309 номерлы; «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 24 июньендәге ПУ-360 номерлы указлары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты структурасын камилләштерү, аның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты мәсьәләләре» 2008 ел, 29 август, 625 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1165 нче; 2011 ел, 21 апрель, 309 нчы; 2013 ел, 19 декабрь, 1010 нчы; 2017 ел, 13 сентябрь, 667 нче; 2018 ел, 12 март, 146 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариаты;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең иң чик санына үзгәреш кертү турында» 2013 ел, 19 декабрь, 1010 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 июнь, 461 нче; 2017 ел, 13 сентябрь, 667 нче;

2018 ел, 12 март, 146 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты структурасына, аны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 19 декабрь, 1010 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 25 июнь, 514 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты -**
**Татарстан Республикасы Хөкүмәте**
**структурасы**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – эшләр идарәчесе

Татарстан Республикасы Премьер-министры секретариаты

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариаты

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариаты

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариаты

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе секретариаты

Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе

Хокук идарәсе

Документлар белән тәэмин итү идарәсе

Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе

Социаль үсеш идарәсе

Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе

Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе

Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе

Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе

Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүмат саклау идарәсе

Мобилизация әзерлеге һәм махсус программалар идарәсе

Җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге

Югары, урта һөнәр белеме бирү һәм фән бүлеге

Сәнәгать бүлеге

Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге

Гомуми тәэмин итү бүлеге

___